**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Гулкин авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№145** **10.12.2024ел.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 февралендәге 92 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы федераль законнар, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Уставына таянып , Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 февралендәге 92 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең:

1.1. 35.1. статьясындагы 10 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән,тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган граждannар ия.».

1.2. 20 статьясындагы 3 өлешенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) белем һәм квалификация турында документ;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Гулкин авыл җирлеге Советы Рәисе С.Д. Инькова